**III ЧАКЫРЫЛЫШ ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МӨСЛИМ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫНЫҢ XLIV СЕССИЯСЕ**

**К А Р А Р № 186**

Мөслим «17» июнь 2020 ел

**Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының муниципаль милегендә торган күчемсез мөлкәтне арендалау шартнамәләре буенча аренда түләвен кичектереп тору шартлары турында**

«Гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү мәсьәләләре буенча Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2020 елның 1 апрелендәге 98-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Күчемсез мөлкәтне арендалау шартнамәләре буенча аренда түләвен кичектерү шартларына һәм срокларына таләпләр билгеләү турында» 2020 елның 3 апрелендәге 439 номерлы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Советы **КАРАР БИРДЕ:**

1. Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы территориясендә урнашкан күчемсез мөлкәтне арендалау шартнамәләре буенча аренда түләвен кичектереп тору шартларын расларга (Кушымта).
2. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының Жир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре палатасы рәисенә йөкләргә.

Мөслим муниципаль
районы Башлыгы,
Мөслим муниципаль районы
Советы рәисе Р.Х. Муллин

Татарстан Республикасы
Мөслим муниципаль районы
Советының 2020 елның
17 июнендәге 186 номерлы
карарына кушымта

Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы территориясендә урнашкан муниципаль милектәге күчемсез мөлкәтне арендалау шартнамәләре буенча аренда түләвен кичектереп тору шартлары

2020 елда күчемсез мөлкәтне файдаланган өчен каралган аренда түләүләрен кичектереп торуның әлеге шартлары «Халыкны һәм территорияләрне табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән яклау турында» Федераль законның 11 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Президенты тарафыннан 2020 елда Татарстан Республикасы территориясендә югары әзерлек һәм гадәттән тыш хәл режимын кертү турында карар кабул ителгәнче, яңа коронавирус инфекциясе таралу нәтиҗәсендә вәзгыятьнең начараюы шартларында аеруча зыян күргән, исемлеге Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2020 елның 3 апрелендәге 434 номерлы карары белән расланган Россия икътисады тармакларында эшчәнлек алып баручы оешмалар һәм шәхси эшмәкәрләр булган арендага алучылар белән төзелгән күчемсез мөлкәтне арендалау шартнамәләренә карата кулланыла (алга таба - аренда шартнамәсе, кичектереп тору) .

Кичектереп тору, торак биналардан тыш, күчемсез мөлкәткә карата бирелә.

Кичектереп тору Татарстан Республикасы территориясендә югары әзерлек яисә гадәттән тыш хәл режимын кертү датасыннан башлап, 2020 елның 1 октябренә кадәр түбәндәге шартларда бирелә:

а) аренда түләве буенча бурыч 2021 елның 1 гыйнварыннан да иртәләмичә һәм 2023 елның 1 гыйнварыннан да соңга калмыйча, этаплап, айга бер тапкырдан да арттырмыйча, күләме аренда шартнамәсе буенча айлык аренда түләвенең яртысыннан артмаган тигез түләүләр белән түләнергә тиеш;

б) кичектереп тору Татарстан Республикасы территориясендә югары әзерлек яисә гадәттән тыш хәл режимы гамәлдә булу вакытына, тиешле чор өчен аренда түләве күләмендә һәм 2020 елның 1 октябренә кадәр Татарстан Республикасы территориясендә югары әзерлек яисә гадәттән тыш хәл режимының гамәлдә булуы туктатылган көннән алып тиешле чорда аренда түләвенең 50 проценты күләмендә бирелә;

в) штрафлар, чит акчалардан файдаланган өчен процентлар яисә арендатор тарафыннан аренда түләвен кертү тәртибен һәм срокларын үтәмәүгә бәйле рәвештә җаваплылыкның башка чаралары (шул исәптән мондый чаралар аренда шартнамәсендә каралган очракларда) кичектереп тору белән бәйле рәвештә кулланылмый;

г) кичектереп торуга бәйле рәвештә арендага алучы тарафыннан түләнергә тиешле өстәмә түләүләрне арендага бирүче тарафыннан билгеләү рөхсәт ителми;

д) кичектереп тору бирелә торган аренда түләве күләме яклар килешүе буенча киметелергә мөмкин;

е) әгәр аренда шартнамәсендә арендага алучы коммуналь хезмәт күрсәтүләрдән файдаланган өчен түләүләрне һәм (яисә) арендага бирелә торган мөлкәтне тотуга чыгымнарны аренда түләвенә кертү каралган булса, Татарстан

Республикасы территориясендә югары әзерлек яисә гадәттән тыш хәл режимы гамәлдә булган чорда арендага бирүче мондый хезмәтләр өчен түләүдән һәм (яисә) мондый чыгымнар тотудан азат ителгән очраклардан тыш, аренда түләвенең күрсәтелгән өлеше буенча кичектереп тору бирелми.

4. 3 пунктта каралган кичектереп тору шартлары мондый килешү төзү датасына карамастан, аренда шартнамәсенә карата өстәмә килешүләргә карата кулланыла.